ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05 декабрь 2024ел № 8133

«Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясы 1 өлешенең 4 пункты, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы Карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы Карары белән расланган муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифларны исәпләү тәртибе турында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. «Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәренең «Шәһәрнең муниципаль учреждениеләрен производство-техник тәэмин итү үзәге» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында» 2019 елның 22 мартындагы 1459 номерлы Карары үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары В.Х. Харисовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов